ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабрь 2019 ел № 6563

Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 номерлы карары белән расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Законы, Шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының өстәмә социаль ярдәм чаралары һәм аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүгә хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 10 мартындагы 1182 номерлы, 2017 елның 14 апрелендәге 2234 номерлы, 2017 елның 24 июлендәге 4318 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 5702 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 5755 номерлы, 2017 елның 23 ноябрендәге 7195 номерлы, 2017 елның 7 декабрендәге 7601 номерлы, 2018 елның 8 августындагы 4481 номерлы, 2018 елның 19 сентябрендәге 5336 номерлы, 2018 елның 26 сентябрендәге 5567 номерлы, 2018 елның 16 ноябрендәге 6757 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 7452 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы 1612 номерлы, 2019 елның 10 июлендәге 3549 номерлы, 2019 елның 27 сентябрендәге 4948 номерлы карарлары редакциясендә) расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасының 7 бүлеге IV бүлекчәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта «Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау, мең сум «2019 ел (мең сум)» графасында «52,0» цифрларын «22,0» цифрларына алмаштырырга;

2) түбәндәге редакциядә 6 пунктны өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Игез балалар туу уңаеннан исем кушу буенча тантаналы чара үткәрү | Башкарма комитет | ел дәвамында | кеше саны | - | - | - | 5 | - | - | 30,0 муниципаль бюджет |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин